| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**Карар** **Решение**

№ 5-2 от «14» ноября 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 03 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставы» нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә 12.11.2016 № 3-12, 12.05.2017 № 8-16, 26.07.2017 № 4-18, 13.11.2017 № 4-19, от 03.09.2018 № 8-28, от 19.11.2018 № 11-29, от 28.03.2019 № 8-32, 30.06.2020 №12-39, 10.06.2021 №8-7; 12.11.2021 №13-9; 12.03.2022 №11-13; 26.04.2023 №18-21; 28.07.2023 №11-22; 27.05.2024 №4-30; 23.03.2025 № 11-13 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.6 статьяның 3,4,5,6,7 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу – вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен; югары белем яки урта һөнәри белем булу – авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

000113

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.»

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Башлыгы В.И.Никитин